**МЕЖРЕГИОНАЛЬНАЯ ОЛИМПИАДА ШКОЛЬНИКОВ «ЮНИОР»**
**ПРЕДМЕТ: ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК**
**ЗАКЛЮЧИТЕЛЬНЫЙ ЭТАП**
**2025–2026 учебный год**
**8 КЛАСС**

# ОТВЕТЫ И КРИТЕРИИ ОЦЕНИВАНИЯ

**Максимальное количество баллов – 50 баллов**

*За правильный ответ 2 балла*

## ЧАСТЬ I.
## Дөрес җавапны сайлап алыгыз (1–10 бирем).

**1. [Ң] авазы**
А) сузык, яңгырау
Б) тартык, яңгырау
В) тартык, саңгырау
Г) тартык, ирен-ирен

**2. ”Җырланган җыр” сүзтезмәсендә кулланылган “җырлаган” сүзе**
А) сыйфат
Б) фигыль
В) сыйфат фигыль
Г) инфинитив

**3. Кеше тавышына, кош-корт, хайван, табигать һәм төрле предмет тавышына охшатып ясалган мөстәкыйль сүз төркеме**
А) аваз ияртеме Б) ымлык В) бәйлек Г) теркәгеч

**4. “Бу күлмәк матур түгел.” җөмләсендә кисәкчәне күрсәт.**
А) бу Б) матур В) күлмәк Г) түгел

**5. Гомумиләштерүче сүзләр тиңдәш кисәкләренең алдыннан килсә, нинди тыныш билгесе куела?**
А) өтер Б) өндәү В) нокта Г) ике нокта

**6. Җөмләнең башка сүзгә буйсынмаган баш кисәге ничек атала?**
А) тәмамлык Б) аергыч В) ия Г) хәл

**7. ”Без, малайлар, 8 класста укыйбыз.” Бирелгән җөмләдә өтер белән аерылган аныклагыч нинди җөмлә кисәге булып килә?**
А) аергыч Б) ия В) хәл Г) тәмамлык

**8. “Өебездә бердәнбер байлыгыбыз, һичшиксез, самавыр иде.” Әлеге җөмләдә өтер куюның дөрес җавабын күрсәт.**
А) эндәш сүз
Б) кереш сүз
В) тиңдәш кисәкләр
Г) аермланган хәл

**9. Бу юллар нинди жанр турында?**
Эпик, лиро-эпик һәм лирик, язмача һәм телдән, көйләп яки көйсез әйтелә торган , икеюллыклардан төзелгән шигъри әсәр. Эчтәлеге белән конкрет тарихи вакыйгаларга һәм тормыш-көнкүреш хәлләренә бәйле.
А) хикәя; Б) әкият; В) бәет; Г) нәсер

**10. Бу шигъри юлның авторы кем?**
“Егет китте, мин калдым
Канын саклап чугымда,
Көн дә аны сагынып,
Балкыйм мин таң нурында”
А) С. Хаким Б) Г.Тукай В) Һ.Такташ Г) М. Җәлил

**Ответы на часть I** (за правильный ответ 2 балла)**:**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Б | А | А | Г | Г | В | А | Б | В | Г |

*За правильный ответ 5 баллов*

## ЧАСТЬ II.

### Мәкальләрне тулыландырыгыз. Төшереп калдырылган сүзләрне яз.

Уйнап сөйләмә, _________________сөйлә.
Яхшы тел яз кебек, ________________көз кебек.
Өең кысан булса да, ________________иркен булсын.
Куркак һәр көн үлә, ______________________бер тапкыр үлә.
Акыллы атын мактар, акылсыз ________________________мактар.

**Ответы на часть II** (5 баллов)**:**
Уйнап сөйләмә, БЕЛЕП сөйлә.
Яхшы тел яз кебек, НАЧАР көз кебек.
Өең кысан булса да, КҮҢЕЛЕҢ иркен булсын.
Куркак һәр көн үлә, БАТЫР бер тапкыр үлә.
Акыллы атын мактар, акылсыз ҮЗЕН мактар.

*За правильный ответ 5 баллов*

## ЧАСТЬ III.

### Татар фразеологизмнарына рус эквивалентларын тап.

| | | | |
|---|---|---|---|
| А | Баш вату | 1 | Душа не лежит |
| Б | Бүре булып уласаң да | 2 | Хоть волком вой |
| В | Йөрәгем ятмый | 3 | У черта на куличках |
| Г | Җил капкасында | 4 | Держи карман шире |
| Д | Тот капчыгыңны | 5 | Ломать голову |

**Ответы на часть III** (5 баллов)**:**

| А | Б | В | Г | Д |
|---|---|---|---|---|
| 5 | 2 | 1 | 3 | 4 |

*За правильный ответ 5 баллов*

## ЧАСТЬ IV.

### Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне яз.

[м], [w], [б], [п] – ______________ тартыклары.
Хикәя фигыльләр өч заманда кулланыла: хәзерге, үткән һәм ________________.
Билгеле бер грамматик формада гына омоним булган сүзләр ____________ дип атала.
Предметның кемнеке икәнен, кайсы затка караганын белдерә торган алмашлыклар ______________ алмашлыклары дип атала.
Сыйфат фигыль – ______________ фигыль.

**Ответы на часть IV** (5 баллов)**:**
[м], [w], [б], [п] – ИРЕН-ИРЕН тартыклары. Хикәя фигыльләр өч заманда кулланыла: хәзерге, үткән һәм КИЛӘЧӘК. Билгеле бер грамматик формада гына омоним булган сүзләр ОМОФОРМА дип атала. Предметның кемнеке икәнен, кайсы затка караганын белдерә торган алмашлыклар ТАРТЫМ алмашлыклары дип атала. Сыйфат фигыль – ЗАТЛАНЫШСЫЗ фигыль.

*За правильный ответ 15 баллов*

## ЧАСТЬ V.

### Иҗади бирем.

**Сезнең каршыгызда хикәянең башы. Хикәяне дәвам итегез. Хикәягезгә берничә кушма җөмлә, туры сөйләм, тиңдәш кисәкләр кертегез.**

«Бу көнне Марат мәктәпкә ашыгып бара иде. Ул кичәге беренче кардан соң туңган күпердән тайпылып төшеп, кулын авырткан иде. Ләкин аның өчен бу көн иң гаҗәп көн булачак икән...»